**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 16 ноябрь № 857

г. Казань

Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү турында

«Россия Федерациясендә гражданнарга социаль хезмәт күрсәтү нигезләре турында» 2013 ел, 28 декабрь, ФЗ-442 нче Федераль законның 8 статьясындагы 16 нчы пункты нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә түбәндәге акчалата түләүләр билгеләргә:

беренче ике елда өзлексез эшләү дәвамында вазыйфаи окладның 10 проценты күләмендә айлык өстәмә түләү;

хуҗалыкны җиһазлауга 20,0 мең сум күләмендә бер тапкыр акчалата түләү.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибен;

Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә өстәмә дәүләт ярдәме чараларын күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган финанс чараларыннан файдалану тәртибе.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының педагогик хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүне гамәлгә ашыру тәртибеннән файдалану буенча аңлатмалар бирергә.

4. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\857.doc